**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

**30.03.2015** **211-п**

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының норматив-хокукый актларына һәм норматив-хокукый актларының проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау хакында**

2009 елның 17 июлендәге “Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге “Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” 96 номерлы Карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге “Аерым норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” 883 номерлы карары нигезендә

боерам:

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының норматив-хокукый актларына һәм норматив-хокукый актларының проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раcларга.
2. Хокукый тәэминат бүлегенә (В.А.Тронин) боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Р.И. Камаловка йөкләргә.

Министр А.Г. Сидоров

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый
ресурслар министрлыгының
2015 елның ____________
№_____ боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының норматив-хокукый актларына һәм норматив-хокукый актларының проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының норматив-хокукый актларына (алга таба – актлар) һәм норматив-хокукый актларының проектларына (алга таба – проект актлары) коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе (алга таба – Тәртип), Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының актларына һәм актларының проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрүне дә кертеп, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының (алга таба – Министрлык) актларына һәм проектларының актларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү процедурасын билгели.

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза Министрлыкның эшләнә торган актлары проектларына хокукый экспертиза үткәргәндә һәм Министрлыкның кабул ителгән актларын мониторинглаганда аларда коррупция күренешләрен ачыклау һәм алга таба аларны бетерү максатларында үткәрелә.

1.3. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен яки конфеденциаль характерга ия булган белешмәләрне үз эченә алучы актларга, актларның проектларына карата үткәрелми.

1.4. Коррупциягә каршы экспертиза көчен югалткан яки гамәлдән чыгарылган норматив-хокукый актларга карата үткәрелми.

1.5. Министрлыкның актларына һәм проектларының актларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүне оештыруның төп принциплары түбәндәгеләр:

1) актларга һәм актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүнең зарури булуы;

2) актны һәм актның проектын башка норматив-хокукый актлар белән үзара бәйләнешендә бәяләү;

3) актларга һәм актларның проектларына карата коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләренең нигезле, объектив булуы һәм тикшерелүе;

4) актларга һәм актларның проектларына карата коррупциягә каршы экспертиза үткәрүче затларның компетентлыгы;

5) актларга һәм актларның проектларына карата коррупциягә каршы экспертиза үткәргәндә Министрлыкның гражданлык җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлеге.

## 2. Актларга һәм актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза

2.1. Коррупциягә каршы экспертиза Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы Карары белән расланган Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы (алга таба – Методика) нигезендә үткәрелә.

2.2. Актларга һәм актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза хокукый тәэминат бүлегенең вәкаләтле заты тарафыннан үткәрелә.

2.3. Коррупциягә каршы  экспертиза акт проекты Министрлыкның структур бүлекчәсеннән алынганнан соң биш көнлек срокта үткәрелә.

2.4. Хокукый тәэминат бүлегенә тапшырылган актларның проектлары

Актларга һәм актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза журналында (алга таба – Журнал) (1 кушымта) тапшырылган көнне үк теркәлә.

Вәкаләтле зат тарафыннан Министрлык актларында аларны куллануны мониторинглаганда коррупция күренешләре ачыкланган очракта, актлар Журналда коррупция күренешләре ачыкланган көнне теркәлә.

2.5. Актка һәм актның проектына коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре хокукый тәэминат бүлегенең вәкаләтле затының бәяләмәсе белән рәсмиләштерелә, ул хокукый тәэминат бүлеге башлыгы тарафыннан имзалана.

2.6. Актта коррупция күренешләре ачыкланганда, бәяләмәдә (2 кушымта) Методика нигезендә ачыкланган барлык коррупция күренешләре дә чагылдырыла.

Бәяләмәдә актта ачыкланган коррупция күренешләрен бетерү ысулы турында тәкъдим булырга тиеш.

Бәяләмә, хокукый тәэминат бүлеге башлыгы имза салганнан соң эш көне дәвамында, Татарстан Республикасының экология һәм табигый ресурслар министрына (алга таба – министр) юллана.

2.7. Министр, актта коррупция күренешләре булу турындагы бәяләмә нәтиҗәләре буенча, аңа үзгәрешләр кертү яки аны гамәлдән чыккан дип тану кирәклеге хакында карар кабул итә.

2.8. Актны эшләгән структур бүлекчә, өч көнлек срокта, ачыкланган коррупция күренешләрен бетерү максатында үзгәрешләр кертү турында Министрлыкның акт проектын яки актны көчен югалткан дип тану турында проект эшли һәм хокукый тәэминат бүлегенә коррупциягә каршы экспертизага җибәрә.

2.9. Коррупциягә каршы экспертизага тапшырылган акт проектында коррупция күренешләре булганда вәкаләтле зат 2 кушымта рәвешендә бәяләмә төзи, коррупция күренешләре булмаганда, 3 кушымта рәвешендә бәяләмә төзи.

Бәяләмә хокукый тәэминат бүлеге башлыгы тарафыннан имзалана һәм акт проектын тапшыручы структур бүлекчәгә җибәрелә.

2.10. Коррупция күренешләре булганда акт проектын эшләгән структур бүлекчә өч көнлек срокта акт проектын җиренә җиткереп эшләп бетерергә һәм аны

яңадан коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен хокукый тәэминат бүлегенә җибәрергә тиеш. Кабат коррупциягә каршы экспертиза өч көнлек срокта үткәрелә.

2.11. Коррупция күренешләре булмаган очракта җиренә җиткереп эшләнгән акт проектында вәкаләтле зат коррупциягә каршы экспертизага тапшыручы структур бүлекчәгә бәяләмә җибәрә.

2.12. Структур бүлекчә (актны эшләүче) җиренә җиткереп эшләнгән акт проектын кызыксынган структур бүлекчәләрнең җитәкчеләренең визалары белән министрга имза салу өчен җибәрә.

2.13. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре Журналда чагылдырыла.

2.14. Министр актны (акт проектын) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган тәртиптә коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлларга хокуклы.

## 3. Актларга һәм актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү

3.1. Министрлыкның рәсми төстә басылып чыккан актлары һәм Министрлыкның Министрлык тарафыннан эшләнә торган һәм “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми www.eco.tatar.ru сайтында (алга таба – сайт) урнаштырылган актларының проектлары коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып тора.

3.2. Министрлык актларының проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен Министрлыкның акт проектын әзерләү өчен җаваплы булган структур бүлекчәсе акт проектын хокукый тәэминат бүлегенә карап тикшерү өчен җибәргән көнгә туры килүче эш көне дәвамында акт проектын, эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен адресны (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау датасын күрсәтеп, сайтта урнаштыра.

3.3. Сайтта урнаштырылган актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү вакыты кимендә биш эш көне тәшкил итә.

3.4. Актка (актның проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча Министрлыкка ирешкән бәяләмә (алга таба – бәяләмә) карап тикшерү өчен Министрлыкның актны (актның проектын) әзерләү өчен җаваплы булган структур бүлекчәсенә җибәрелә.

3.5. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә киңәш бирү характерына ия һәм Министрлык тарафыннан зарури рәвештә каралырга тиеш. Бәяләмәне алганнан соң 15 көнлек срокта Министрлыкның структур бүлекчәсе ирешкән бәяләмәне карый һәм коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны үткәргән юридик яки физик затка нигезле җавап юллый, бәяләмәдә ачыкланган коррупция күренешләрен бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан гайре.

3.6. Актка (актның проектына) карата коррупциягә каршы бәйсез экспертиза барышында ачыкланган коррупция күренешләре Министрлыкның актны (актның проектын) әзерләү өчен җаваплы булган структур бүлекчәсе тарафыннан бетерелә.

3.7. Кисәтүләрне бетергәннән соң һәм коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән тәкъдимнәрне исәпкә алганнан соң, Министрлыкның акт проектын әзерләү өчен җаваплы булган структур бүлекчәсе коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча ирешкән бәяләмәләрне теркәп, хокукый тәэминат бүлегенә акт проектын яңадан карау өчен тапшыра. Яңадан карап тикшерү өч көнлек срокта башкарыла.

3.8. Әгәр дә коррупция күренешләре актта ачыкланса, Министрлыкның әлеге актны эшләгән структур бүлекчәсе актка үзгәрешләр кертү яки аны көчен югалткан дип тану өчен чаралар күрә.

3.9. Министрлык, Министрлыкның актларында һәм Министрлык тарафыннан эшләнгән актларның проектларында коррупция күренешләре барлыгын таныклый торган коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, Министрлык законнарда билгеләнгән тәртиптә аталган актларны (актларның проектларын) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең ризасызлыгын нигезләгән аңлатма язуын теркәп, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына коррупциягә каршы экспертизага җибәрә.

3.10. Эшләүче аның тарафыннан эшләнгән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясенең Федераль Җыелышының Дәүләт Думасына кертелә торган федераль закон проектларында, Татарстан Республикасы закон проектларында, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында коррупция күренешләре барлыгын таныклаучы коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән риза булмаган очракта, эшләүче аталган норматив-хокукый актларның проектларын карап тикшерү өчен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшыра.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый
ресурслар министрлыгының
2015 елның 30 мартындагы
211-п номерлы боерыгы белән
расланган Татарстан
Республикасы Экология һәм
табигый ресурслар
министрлыгының норматив-
хокукый актларына һәм
норматив-хокукый актларының
проектларына коррупциягә
каршы экспертиза үткәрү
тәртибенә карата
1 кушымта

**Коррупциягә каршы экспертизага тапшырылган норматив-хокукый актларны һәм норматив-хокукый актларның проектларын исәпкә алу**
**ЖУРНАЛЫ**

| Актны (актның проектын) экспертизага кабул итү датасы | Актны (актның проектын) әзерләгән структур бүлекчә исеме | Актның (акт проектының) исеме | Коррупция күренешләре булу/булмау | Экспертиза үткәрү вакыты | Бәяләмә әзерләү вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый
ресурслар министрлыгының
2015 елның 30 мартындагы
211-п номерлы боерыгы белән
расланган Татарстан
Республикасы Экология һәм
табигый ресурслар
министрлыгының норматив-
хокукый актларына һәм
норматив-хокукый
актларының проектларына
коррупциягә каршы
экспертиза үткәрү тәртибенә
карата
2 кушымта

Хокукый тәэминат бүлеге

Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә

______________________________________________
актның (акт проектының) исеме

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы 2009 елның 17 июлендәге “Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” 172-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 3 өлеше нигезендә, коорупциягә каршы экспертиза үткәрелде

______________________________________________
актның (акт проектының) исеме

(алга таба - ______________________________________________).
(кыскача)

Тапшырылган______________________________________________).
(кыскарча)

коррупция күренешләре ачыкланды.

Ачыкланган коррупция күренешләрен бетерү максатларында түбәндәгеләр тәкъдим ителә

______________________________________________
(коррупция күренешләрен бетерү ысулы күрсәтелә)

| | | |
|---|---|---|
| ______________________ | ______________ | ______________ |
| (хокукый тәэминат бүлеге башлыгы) | (имза) | (Ф.И.А.) |

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый
ресурслар министрлыгының
2015 елның 30 мартындагы
211-п номерлы боерыгы белән
расланган Татарстан
Республикасы Экология һәм
табигый ресурслар
министрлыгының норматив-
хокукый актларына һәм
норматив-хокукый
актларының проектларына
коррупциягә каршы
экспертиза үткәрү тәртибенә
карата
3 кушымта

Хокукый тәэминат бүлеге

Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә

___________________________________________________
актның (акт проектының) исеме

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы 2009 елның 17 июлендәге "Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында" 172-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 3 өлеше нигезендә, коорупциягә каршы экспертиза үткәрелде

___________________________________________________
актның (акт проектының) исеме

(алга таба - ________________________________________).
(кыскача)

Тапшырылган ________________________________________).
(кыскача)

коррупция күренешләре юк.

______________________ ______________ ______________

(хокукый тәэминат бүлеге башлыгы) (имза) (Ф.И.А.)